**Бөек Җиңүгә 67 ел!**




# Ватаным сагында данлы авылдашларым

**Арча районы Шекә авылы**

***“Ватаным сагында данлы авылдашларым”***

**Автор** – Шушмабаш урта мәктәбенең беренче квалификацион категорияле укытучысы **Нуриева Рәмлә Равил кызы**.

Брошюраны әзерләүдә Шушмабаш урта мәктәбе укучылары катнашты.

Арча районы Шекә авылының данлы шәхесләре хакында.

**Бөек җиңүнең 67 еллыгына багышлана.**

**1945-2012**



**Бүген без үлгәннәрне хөрмәт белән искә алабыз, рухларына дога кылабыз, исәннәрне кадерлибез, чөнки бүген- Бөек җиңү бәйрәме. Бәйрәм көнендә генә түгел, һәркөн тоеп яшәсеннәр иде алар безнең хөрмәтебезне, картлыклары тыныч һәм бәхетле булсын , дип телибез...**



Быел Бөек Ватан сугышы беткәнгә 67 ел. Ә сугыш үзенең ачлыгы-ялангачлыгы, мәрхәмәтсезлеге белән күңелләрне әле дә өшетә. Җиңү көне җиңел бирелмәде! Безгә җиңү бүләк иткән авылдашларыбыз даны мәңге сакланыр. Шекә авылыннан сугышка 128 кеше киткән, шуның 68е кире әйләнеп кайткан, 60ы сугыш кырларында мәңгегә ятып калган. Бу китапчыкта без кайбер данлы авылдашларыбызның истәлекләренә тукталырбыз..

# Исәннәрнең кадерен белик



**Кәримов Хәбир абый** 1925 елда Шекә авылында туа. 1942 елда әниләре үлә. Әтиләре 4 баланы калдырып, фронтка китә. 1943 елның 23 январенда Хәбир абый үзе дә авылдашы Ризванов Мөхәммәтҗан белән бергә сугышка чыгып китә. Арчадан Чувашиягә озаталар. Монда хәрби хәзерлек узалар. Аннан Горький шәһәре тирәсендәге Гороховец лагеренда булалар. Биредә ашау начар, хәрби хәзерлек бик көчлебула, землянкаларда яшиләр.Аннан 2нче Балтыйк буе фронтына билгелиләр. Снайпер булып хезмәт итә ул. Фронтның иң алгы сызыгында була. 1944 елның 31 январенда бик каты яралана. Уң аягын кисәргә туры килә. 8 ай буе госпитальләрдә дәвалана. 1944 елның сентябрендә, култык таяклары белән, Арча белән ике араны ике көндә узып, Шекәгә, туган йортына кайтып төшә.Гаилә кора. Тормыш иптәше Рәшидә апа белән 11 бала тәрбияләп үстерә. Бүгенге көндә улы Хәниф гаиләсе тәрбиясендә матур гына гомер итә.





**Нуриев Әсгатьнең сугышчан юлы**
**1942-1947**



Әсгать абый сугышчан дуслары, аларның туганнары белән очрашуда, 1999 ел.

# Исәннәрнең кадерен белик



**Ризванов Мөхәммәтҗан** 1925 елда Шекә авылында туа. Сугыш башланганда аңа 16 яшь була. Әтисе Ризван абый 1941 елда ук сугышка китә һәм хәбәрсез югала. Мөхәммәтҗан абый үзе сугышка 1943 елда алына. Командир-сержантлар әзерләү курсын үткәч, 2нче Балтыйк буе фронтына җибәрелә. 1944 елның 13 мартында каты яраланып, госпитальгә эләгә. Баш арты, муены каты яраланган була, операция ясап, ярчыкларны чүплиләр. Документлары югалу сәбәпле, өенә хәбәрсез югалуы турында хәбәр килә. 7 ай дәваланганнан соң 1944 елның 9 октябрендә Шекә авылына кайтып төшә. 1947 елда Ташкичү авылы кызы Рәхимә апа белән тормыш кора. 6 бала тәрбияләп үстерәләр. Алар бүгенге көндә дә тигез, матур гомер кичерәләр. Уллары Рифат гаиләсе тәрбиясендә яшиләр.

# Исәннәрнең кадерен белик



**Хәкимов Сабирҗан Хәкимҗан улы** 1928нче елның 1нче маенда Шекә авылында туа.

1949нчы елның 19нчы маенда Армиягә алына.1951нче елга кадәр Забайкальеда хезмәт итә.Зенит-артиллерия частенда разведчик-орудиец була ,1951нче елның апреленнән 1953нче елның апреленә кадәр Төньяк Корея сугышында катнаша. 1951нче елның 12 нче июнендә җиңелчә яралана, контузия ала.

Сабирҗан абый 1953нче елда туган авылына- Шекәгә кайта. 1964нче елдан лаеклы ялга чыкканчы , сәүдә эшендә эшли.

Хатыны Галимә апа белән 5 бала тәрбияләп үстерделәр. Хәзерге вакытта Сабирҗан абый Шекә авылында улы Рафил һәм килене Кәримә тәрбиясендә яши.

1943 елның 3 маенда Әсгать абый яңадан сугышка чыгып китә. Бу юлы аңа Ленинград блокадасын кичерергә туры килә. Авырлыгы 32 кг га гына кала, күп авырлыклар кичерә. Германиягә кадәр барып җитә.

1947 елның мартында хәрби хезмәтен тәмамлап туган якларына кайта һәм күп еллар шофер булып эшли.

2003 елның 6 апрелендә вафат булды.

Әсгать абыйның сугышчан бүләкләре:

“За боевые заслуги” медале, II-III дәрәҗә дан орденнары, “Отечественная война” ордены, “Участник операции “Нева””билгесе, “СССРның кораллы көчләренә 60 ел ” медале, “Җиңүгә 40 ел” медале, “Ленинград блокадасы участнигына”, “Невский плацдарм ”билгесе,

“ 28 миномет Ленинград бригадасы ветераны” ветеран значогы



.

Авылдашыбыз Нуриев Әсгать Нурмөхәммәт улының хатирәләренә тукталып китик әле

**Әсгать абый сөйләгәннәрдән...**



1941 елның җәе. Уңыш яхшы, тиздән җыеп аласы. Ләкин авылга коточкыч хәбәр килеп җитте: фашист Германиясе безнең илгә сугыш башлаган.
1942 елның 2 маенда Әсгать абый авылдашы Вилданов Җамалетдин белән сугышка чыгып китә. Башта Ижевск шәһәрендә комсоставка укый, аннан Тамбов шәһәрендә сугышка әзерләнә.
1942 елның 6 сентябрендә авылдаш дусты Бариев Әхәт белән Кавказда беренче сугышка керә. 3 ай 14 көн буе Майкоптан Туапсе шәһәренә кадәр чигенәләр. Кыш бик суык була. Аякларын өшетеп, Әсгать абый Сочи госпиталенә эләгә, аны 6 айга Шекәгә кайтарып җибәрәләр.

# Исәннәрнең кадерен белик



**Шәйхиев Хәертдин**

1919 елның 23октябрендә Балтач районы Яңгул авылында туа. Хезмәт юлын Яңгул урта мәктәбендә укытучы булып башлый.

1942 елның апрелендә сугышка алына. 1942елның ахырында, авыру сәбәпле, сугыштан азат ителә. Кайтуга ук, МВДга эшкә билгеләнә, рядовойдан милиция начальнигы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә.

1954 елны Хәертдин абыйны Шекә авылына “Көрәш” колхозының председателе итеп билгелиләр. 1957-1958 елларда “Северный” совхозының Шекә бригадасынды бригадир булып эшли.

”За победу над Германией”, “За победу над Японией”, “За безупречную службу в МВД СССР”,”Отличник милиции”һәм күп юбилей медальләре бар.

Бүгенге көндә Хәертдин абый хатыны Асия апа белән улы Илгиз һәм килене Фәймә тәрбиясендә Шекә авылында яши.

# Үлгәннәрнең каберен белик...





**Фатхрахманов Зәкәрия абый** 1912 елда Шекә авылында туа. 1934-36 елларда армиядә хезмәт итә. 1939 елда 8 ай буе Фин сугышында була. 1941елда Бөек Ватан сугышына китә. Ленинград блокадасында кавалерия частендә хезмәт итә. Соңрак саперлар частенә билгеләнә. 3 тапкыр каты яралана, контузия ала. 1944 елда туган авылына кайта. Сугышчан батырлыклары өчен I дәрәҗә дан ордены, “За оборону Ленинграда” медале, Кызыл йолдыз ордены белән бүләкләнгән. 1нче фотода Зәкәрия абый сугышчан дусты, Теләче районы Татар Тәмтесе авылы егете Хөсәенов Хәсән белән Ленинградта төшкән(1942ел). 2нче фотода тормыш иптәше Тайфә апа белән..

**Нуриева Нажия апа сөйләгәннәрдән**: “Ачлык, ялангычлыкны күп күрдек. Әтием сугышка китеп исән-сау әйләнеп кайтты, шөкер, ләкин ике абыем сугышта үлеп калды. Сугыш бик аяусыз, якын туганнарыңны тартып ала, тормышның ямен ала. Сугыш башланганда миңа 12 яшь иде. Кече яшьтән иң авыр эшләрне дә эшләргә туры килде. Әнием дога язып бөти ясап бирде һәм шуны сакларга кушты. Бу дога мине сугыштан соң да саклап йөргәндер, яман кешеләргә юлыкмадым. Хәзер тормыш рәхәт инде, илләр тыныч булсын!”

Менә шундый изге теләкләр белән безне озатып калды ак яулыклы күпне күргән ак әбиләр-тыл ветераннары. Без аларга сәламәтлек телибез.



**Нуриев Әсгать абыйның тормыш иптәше Нуриева Рәшидә апа белән очрашу**

9 май бәйрәме якынлашканда без каһарман авылдашларыбызны, тылда эшләгән әби-апаларыбызны күңелебездән барлыйбыз һәм классыбыз белән өйләренә барып, аларның хәлләрен сорашабыз, сугыш елларындагы хатирәләрен тыңлыйбыз. Нуриева Рәшидә апа сөйләгәннәрдән: “Сугышның авырлыкларын искә төшерергә дә куркыныч. Без ул хәбәрне ишеткәч, югалып калдык.. Сугыш бездән этиебезне тартып алды. Ил белән күтәргән хәсрәт булгач, түздек инде. Дөньялар тыныч булсын. Ул дәһшәтне сезгә күрергә язмасын...”



# Үлгәннәрнең каберен белик...



**Габдрахманов Әфләтун абый** 1925 елда туа. 1943 елда армиягә алына. Аларны 2нче Ерак Көнчыгыш фронтына җибәрәләр. 1945 елның августында Кытай җирендә барган сугышларда катнаша. 1946 елның октябрь аена кадәр Харбин шәһәрендә була. 1946 елда исән-сау килеш туган якларына кайта. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен «Ватан сугышы» орденына һәм медальләргә ия була. Тыныч тормышта күп еллар күмәк хуҗалыкта ветеренария врачы булып эшли. Тормыш иптәше Әнвәр апа белән 7 бала тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә вафат.

# Үлгәннәрнең каберен белик...



**Бәширов Кәрим абый** 1925 елда Апаз авылында туа. 1943 елның 10 январенда сугышка чыгып китә. Аларны Арчадан Ерак Көнчыгышка озаталар. Җиңү көне килсә дә тиз генә туган ягына кайта алмый әле ул. 1945 елның сентябреннән 1нче Кызыл байрак исемендәге армиянең300нче дивизиясе составында Япон империалистларына каршы Манчжурия җирендә разведчик булып хезмәт итә. Каты сугышлар барышында, снаряд шартлап, балчыкка күмелеп кала. Исән калган командиры казып чыгарганда ул аңында булмый. Авыр контузия алып, госпитальгә элэгә. Дәваланып чыккач, Харбинны алуда катнаша. 1950 елда демобилизацияләнеп, авылга кайта. Шекә мәктәбенә укытырга килә һәм шушында төпләнеп кала. Тормыш иптәше Халидә апа белән 5 бала тәрбияләп үстерә. 2007 елда вафат булды.


# Үлгәннәрнең каберен белик...



**Нуриев Кави Нурмөхәммәт улы** хәрби хезмәткә алынгач күрше авыл кешесе Егоров Павел абый белән икесе Суслонгер лагеренә эләгәләр. Биредә күп кыенлыклар күрәләр. Бу лагерь таратылгач, Нуриев Кави абый Кемерово шәһәрендә хәрби заводта кораллар ясарга җибәреләр, “ябык” заводта йозак астында эшлиләр алар. Сугыштан соң да күп еллар хәрби серне ачмый, хәтта якыннарына да үзе эшләгән завод турында сөйләргә яратмый ул.

Тыныч тормыш башлангач, күп еллар күмәк хуҗалыкта хезмәт куя. Авылдашлар аны киң күңелле, ярдәмчел, хезмәт сөючән кеше итеп искә алалар. 1980 елның 28 августында Нуриев Кави Нурмөхәммәт улы вафат булды.

## Фронттан килгән шомлы хәбәрләр...



"Дубликат"
Первое извещение
выдано 5-II-46 г.

Арский
районный военный
комиссариат
Татарской АССР
6 мая 1965 г.
№ 4/543
г. АРСК, Татарской АССР


ИЗВЕЩЕНИЕ

Ваш муж, красноармеец Хайруллин
/муж, сын, брат, военное звание, фамилия,
Назип Хайруллович 1914 года
имя и отчество/.
рождения, уроженец: Тат. АССР, Арский район
дер. Шека, находясь на фронте Великой
Отечественной войны пропал без вести
в апреле 1944 года.

ОСНОВАНИЕ: Извещение Упр. по учету от "30" октября
1946 г. за 765463

Настоящее извещение является документом для возбуждения ходатайства о пенсии.

АРСКИЙ РАЙВОЕНКОМ
-подполковник- /ХРИСТОФОРОВ /.



Авылдашыбыз Хәйруллин Нәҗип Хәйрулла улының хатыны Майшәрәф апага һәм кызы Мансурага фронттан язган хатлары һәм 1944 елда хәбәрсез югалганлыгы турында белешмә. Мансура апа аларны кадерле ядкарь итеп саклый.

# Үлгәннәрнең каберен белик...



**Камалов Гарапша абый** 1943 елның 9 октябрендә 17 яшендә сугышка китә. Башта 6 айлык укуларга эләгә. Шартлар бик кырыс була: ачлык, хәлсезлек. 6 ай узганчы ук Гарапша абый үзе теләп, сугышка китә.Смоленск өлкәсенең Вязьма шәһәренә китерәләр.2 танк корпусына пополнение булып урнашалар. 1943 елның 15 февралендә Днепрны кичеп чыгып, Минскка таба китәләр. Сугышта ул шофер, танкист була. Берничә тапкыр яралана, авыр контузия ала. Германиянең Дрезден шәһәренә кадәр барып җитә. Эльбада 9 май көнне Җиңү сәгатен күрергә насыйп була. Сугышчан бүләкләре бар. Бүгенге көндә вафат.

# Үлгәннәрнең каберен белик...



**Хабибрахманов Рөстәм абый** 1925 елда Казан шәһәрендә туа. 1943 елда сугышка китә. 1944 елның маена кадәр Япония чигендә хезмәт итә. Ижевск шәһәренә күчереп, станоклы пулеметтан атарга өйрәнүләр узганда сержант исемен бирәләр. 6 айлык әзерлектән соң Минск шәһәренә җибәрәләр. 1944 елның декабрендә Польша җирләрен фашист илбасарларыннан азат итүдә катнаша. Көнчыгыш Пруссиядә Мариенбург шәһәрен азат иткәндә каты яралана, 3 ай госпитальдә ятып чыга һәм 1945 елда авылга кайтып төшә. Батырлыклары өчен II дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнгән. Тыныч тормышта күп еллар күмәк хуҗалыкта бригадир, ферма мөдире вазифаларын башкара. Тормыш иптәше Миңзифа апа белән 10 бала тәрбияләп үстерәләр.2008 елда вафат булды.

# Һәркем җиңү көнен якынайтты.

Сугыш... Безгә өлкәннәрдән ишетеп, тарих битләреннән укып кына мәгълүм булса да без аның шомлы, куркыныч, котсыз булуын аңлыйбыз. Ул һәр гаиләгә үзенең салкын кулы белән кагылган. Фронтта һәм тылда барлык ил халкы җиңүне якынайтыр өчен үзен-үзе аямаган. Без укучылар белән Җиңү бәйрәме якынлашу уңаеннан үзебезнең гаиләләрдәге өлкәннәрдән бу дәхшәтле еллар турында сорашып, мәгълүмат тупладык. Сугыш чоры балалары әниләре белән кырга эшләргә чыкканнар, ул вакытта бөтен авыр эшне хатын-кызлар, яшүсмерләр, картлар эшләгән, чөнки ирләр сугышта булган. Кайбер хатын-кызлар хәтта тракторны “иярләгән”. Көне буе эшләп, арып кайтсалар да кичләрен җыелышып, фронттагылар өчен бияләйләр, носкилар бәйләгәннәр.

# Үлгәннәрнең каберен белик...



**Рәхимжанов Мәгъсүм абый** 1941 елның июнендә фронтка китә. Авыр яраланган хәлдә әсирлеккә эләгә. Лагерьдан лагерьга куылып йөртүләр, таш карьерларында авыр хезмәт, барысын да күрә ул. Бервакыт Мәгъсүм абый эләккән концлагерьда хәбәр тарала: фашистлар совет әсирләреннән Кызыл Армиягә каршы көрәшү өчен хәрби частьлар төзергә җыеналар икән. Шул максаттан оештырылган татар легионы арасында Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре киң пропаганда эшләре җәелдереп җибәрәләр. Мәгъсүм абыйны татар легионының беренче батальонына билгелиләр. 1943 елның февралендә партизаннарга каршы җибәрелгән батальон немец офицерларын кырып бетерә һәм үзебезнекеләргә кушыла. Мәгъсүм абый 10 ай партизаннар арасында сугыша, аннары Курск дугасына эләгә. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Мәгъсүм абый 1944 елда III дәрәҗә Дан ордены, 1946 елда “За победу над Германией ”, Iдәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнә. 1996 елда Мәгъсүм абый вафат булды.

Үлгәннәрнең каберен белик...



**Василов Фәрит абый** 1926 елда Шекә авылында туган. 1943 елда сугышка алына. Свердловск шәһәрендә 6 айлык өйрәнүләр уза. Беренче сугышчан чыныгуны Фәрит абый Польша җирләрендә ала. Берлинга кадәр барып җитә. Мина шартлап аягы нык имгәнә. 3 ай Кенигсберг шәһәрендә госпитальдә ята, аннан 9 ай Польшада дәвалана. Ялгызы гына кайтырлык сәламәтлеге булмаганлыктан, аны бер солдат озата кайта. Сугыш яралары гомер буе әрни. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен IIнче,IIIнче дәрәҗә дан орденнары, күп кенә медальләр белән бүләкләнә. 1951 елда Мәгъмүрә апага өйләнә, 5 бала тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә Фәрит абый вафат.

# Үлгәннәрнең каберен белик...




Мәрдәнов Гыйнният абый  1921 елда Шекә авылында  туа, 1942 елның мартында сугышка китә. Мари АССРның Сурук станциясе 133 нче запас полкта хәрби өйрәнүләр уза. Шуннан Волхов фронтына җибәрелә. Анда аягы яралана, дәваланып чыга һәм яңадан сугышка керә. Ржев шәһәре өчен көрәшкәндә, каты яраланып,  аягын тубыктан кистерә. Озак дәваланганнан соң, Чусовой шәһәрендә аңа протез ясап бирәләр. Бер аяксыз инвалид һәм бер күзенә осколок тиеп сукырайган хәлдә туган йортына кайта Гыйнният абый. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен ул Iнче һәм IIнче дәрәҗә дан ордены, күп санлы медальләр белән бүләкләнә. Сугыштан кайткач, озак еллар күмәк хуҗалыкта эшли. Бүгенге көндә вафат.

# Үлгәннәрнең каберен белик...



**Гайнетдинов Ибраһим абый** 1916 елда туган. 1941 елның көзендә Кенәрдә машина-трактор паркында ремонт ясаган вакытында аны сугышка алып китәләр. Шекәгә кайтып, туганнары белән хушлашырга да өлгерми кала.  Иң элек  Оренбург шәһәрендә 1 ай сугышка әзерлиләр аларны. Төз атарга өйрәтәләр. Мәскәү асты сугышында ике кулы да яралана. Дәваланып чыккач, Калинин һәм Смоленск шәһәрендә оборона эшен алып баралар. 1942 елның августында Ржев шәһәре өчен каты сугышлар барганда, ике аягы да яралана. Ул Иваново шәһәрендәге госпитальдә 4 ай буе ятып чыга.1943 елның 1 январендә демобилизацияләнә һәм туган ягына кайта. 1946 елда Нажия исемле кызга өйләнә. 4 бала тәрбияләп үстерәләр.Сугыш вакытында күрсәткән батырлыклары өчен орден һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнә. Бүгенге көндә вафат.

# Үлгәннәрнең каберен белик...



**Кавиев Самат Кави улы**

1917 елда Шекә авылында туа.

1941 елда сугышка киткән. Сугышта ул сапер булган.

1942 елда каты яралана. Снаряд кыйпылчыгы тиеп кулбашын имгәтә. Бик озак Сәмәрканд госпиталендә дәваланганнан соң, демобилизацияләнеп туган якларына кайтып төшә. Сугыштан соң 37 ел буе мәктәптә укытучы булып эшли. Сугыш яралары гомере буе әрни. Кавиев Самат абый I дәрәҗә “Ватан сугышы” ордены, “За боевые заслуги”, “За отвагу” медальләре лауреаты.

# Исәннәрнең кадерен белик...



**Кавиева Мансура Муллавәли кызы** 1926 елда Арча районы Иске Кенәр авылында туа. 1941-1945 елларда Казандагы 3995 нче номерлы хәрби госпитальдә эшли. Бу госпиталь вокзалдагы мәктәп бинасында урнашкан була. Мансура апа бу госпитальдә санитарка вазифаларын башкара. Кер дә уа, ашарга да пешерә, палаталарны да җыештыра , авыр яралыларга көченнән килгәнчә ярдәм дә күрсәтә Мансура апа биредә. 1945 елның көзендә авылына кайта. 1947 елда Кавиев Самат абыйга тормышка чыга. Бүгенге көндә улы Рәфкать һәм килене Халидә тәрбиясендә матур гына гомер итә.

# Үлгәннәрнең каберен белик...


Серия Т

в том, что он по освидетельствовании

«27» февраля 1956 г.

комиссией при Кзыл
(указать при
каком РВК или воинской части)

признан негодным к несению воинской обязанности с исключением с учета по гр. «I» ст. «53а» расписания болезней приказа МВС СССР № 130 1951 года и снят с воинского учета.

3

Серия Т

Подлежит переосвидетельствованию

через

Личная подпись владельца Кавиев

М. П.

Районный Военный комиссар

к-н. /Синельников/
(звание, фамилия)

Начальник 1 части

к-н. (звание, фамилия)

«27» февраля 1956 года

4

**Кавиев Самат Кави улының хәрби билеты.**



**Вильданов Гыйльман Вильдан улы** 1917 елның 18 декабрендә Шекә авылында туган. 1941 елның 14 августында Гыйльман абый сугышка китә. Сугышчан юлы Үзәк фронтта 498 нче номерлы “Красный стрелок” полкында башлана. Каты яраланганнан соң, 1941 елның ноябрендә Кызыл Армиянең хезмәт батальонының 21нче бүлекчәсенә күчерелә. 1942 елның июлендә, чолганышта калып, әсирлеккә эләгә. Бик күп авырлыклар күрә. Хәрби документларыннан күренгәнчә, 1945 елның 9 маенда гына әсирлектән котыла ул. 1946 елның 14 маенда демобилизацияләнеп, туган авылына исән-сау кайту бәхетенә ирешә. 1978 елның 11 декабрендә Гыйльман абый вафат булды.